- Ф.Садриев – публицист;
- Ф.Садриев – юмор остасы;
- Ф.Садриев иҗатының тәрбияви әһәмияте.

Фоат Садриев иҗаты һәм XXI гасыр мәктәбе (укытучыларның фәнни-эзләнү эшләре өчен)

- Ф.Садриев иҗатын өйрәнү юнәлешендәге иҗади проектлар, презентацияләр;
- Мәктәптә Ф.Садриев иҗатын өйрәнү тәҗрибәсеннән чыгып эшләнгән электив курс программалары;
- Ф.Садриев иҗатын мәктәптә өйрәнү тәҗрибәсеннән мастер-класс.

5. Хезмәтнең язылу тәртибе

Эшләр татар телендә, текстның күләме 8 басма биттән артмаска тиеш. Эзләнү эшендә материаллар рәсем, схема һәм карта, фотосурәтләр булырга мөмкин, күләме 5 бит). Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman – 14. Полялар: сулдан - 30 мм, уңнан-15мм, астан һәм өстән-20 мм. Юл араларында 1,5 интервал кала. Кызыл юл 1 см калдырылып башлана) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла.

Титул битенә белем бирү оешмасының тулы исем (устав буенча), район, укучының яки укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, тема язылы.

6. Оештыру взносы – 300 сум

7 . Бәяләү критерийлары

- проблеманы чишүнең тирәнлеге, тулылыгы, үзенчәлекле ысуллары кулланылган булуы;
- логик яктан дөрес фикерләү, ышандырырлык, дәлилләнгән нәтиҗәләр ясау;
- эшнең фәннилеге;
- эшнең максатын дөрес билгеләү;
- авторның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе;
- чыгышның композицион бөтенлеге, дәлилли белү, теманы ача белү дәрәҗәсе;
- чыгышны күрсәтмә материаллар белән баету;
- заман таләпләренә туры килүе;
- чыгыш ясаучының сөйләм, аралашу культурасы.

Чыгыш ясау өчен 5-7 минут вакыт бирелә. Шул вакыт эчендә укучы төп фикерләрне кыска һәм төгәл итеп җиткерә белергә тиеш.

7. Фоат Садриев укуларын йомгаклау һәм нәтиҗә ясау:

Төбәкара Фоат Садриев укуларында катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Катнашучыларның чыгышларын тыңлап бетергәннән соң, эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Эксперт комиссиясенең карары турында беркетмә язылы.

8. Катнашучыларны бүләкләү

Фоат Садриев укуларында катнашучыларга сертификатлар, җиңүчеләргә Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге, Татарстан Республикасы язучылар Союзы, Мөслим муниципаль районының мәгариф бүлегенең дипломнары, нәтиҗәле чыгыш ясаучыларга рәхмәт хатлары тапшырыла.

I Төбәкара “Фоат Садриев укулары – 2014” оештыру комитетына гариза

Укучыларны тәкъдим итүче белем бирү оешмасы (Устав буенча) _____

Белем бирү оешмасының электрон адресы_____